**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШИЛЬНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

28 декабрь, 2019 ел Шильнәбаш авылы № 40

Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ санлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 880 санлы карары,Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнәбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 29март №33/2 «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнәбаш авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләреннән, физик һәм юридик затларның хосусый милегендә булган җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 21 санлы карары, Шильнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 8 декабрь «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»

**КАРАР БИРӘ:**

1. Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыскартуга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтадагыча расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегендә, мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районынынң рәсми сайтында, авыл җирлекләре бүлегендә (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Таттарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе О.А. Гончарова